ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2024 елның 19 октябре № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлегендә Горшково авылы халык җыены

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлегендә Горшково авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, контракт буенча хәрби хезмәт узучы Россия Федерациясе Кораллы көчләре хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә 2025 елга үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (кышкы чорда юлларны кардан чистарту (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), җәйге вакытта юлларны чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, бензотриммерларга запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (материаллар, скважинага павильон сатып алу, урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү).

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуция челтәрендә «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында ": https://pravo.tatarstan.ru., «Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Горшково авылы, Күл арты урамы, 35А йорт мәгълүмат стендында кабул ителгәннән соң 10 эш көне дәвамында игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге башлыгы С.Ю.Питеркина

Р 06-585/14 СОВЕТ ЛЕНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ